ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14 ноябрь, 2025 ел №2/6

Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 18 апрелендәге 31/13 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28, 48, 49 статьялары нигезендә
Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 18 апрелендәге 31/13 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2009 елның 9 апрелендәге 40/23, 2012 елның 20 сентябрендәге 21/11, 2013 елның 29 августындагы 26/15, 2015 елның 22 октябрендәге 2/19, 2016 елның 15 декабрендәге 13/11, 2018 елның 10 августындагы 26/14, 2019 елның 7 октябрендәге 33/14, 2020 елның 6 февралендәге 36/8, 2021 елның 27 маендагы 7/10, 2023 елның 29 мартындагы 22/9, 2023 елның 6 декабрендәге 28/10 номерлы Карарлары редакциясендә) 7.1 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча хезмәт стажына карата:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча – бер елдан да ким булмаган муниципаль хезмәт стажы яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча ике елдан да ким булмаган хезмәт стажы булу;

муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары буенча – бер елдан да ким

булмаган муниципаль хезмәт, белгечлек,әзерлек юнәлеше буенча хезмәт стажы булу.

Муниципаль хезмәтнең әйдәүче, өлкән һәм кече вазыйфаларына муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча хезмәт стажына карата квалификация таләпләре билгеләнми.»

2. Әлеге Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 17 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев